КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 24 гыйнвар г.Казань № 39

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 20 май, 410 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе һәм «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт командировкаларына бәйле булган чыгымнарны каплау тәртибе һәм күләмнәре турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт командировкаларына бәйле булган һәм башка урынга эшкә күчкәндәге чыгымнарны каплау тәртибе һәм күләмнәре турында» 2019 ел, 20 май, 410 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 29 декабрь, 1726 нчы; 2025 ел, 30 июль, 554 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе һәм «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт командировкаларына бәйле булган чыгымнарны каплау

тәртибе һәм күләмнәре турындагы нигезләмәгә, 21[1] пунктның «а» пунктчасындагы «Уртача эш хакын исәпләп чыгару тәртибе үзенчәлекләре турында» 2007 елның 24 декабрендәге 922 номерлы» сүзләрен «Уртача эш хакын исәпләп чыгару тәртибе үзенчәлекләре турында» 2025 елның 24 апрелендәге 540 номерлы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин